КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 сентябрь г.Казань № 935

Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне расларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасының төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары сакланышын тәэмин итүгә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2016 ел, 28 июль, 522 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары сакланышын тәэмин итүгә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2016 ел, 28 июль, 522 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары сакланышын тәэмин итүгә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәреш кертү һәм Юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан кулланыла торган җитештерү объектларын Татарстан Республикасының төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары сакланышын тәэмин итүгә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештырганда билгеле бер риск категориясенә кертү критерийларын раслау хакында» 2018 ел, 31 октябрь, 969 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары сакланышын тәэмин итүгә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2016 ел, 28 июль, 522 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары сакланышын тәэмин итүгә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәреш кертү хакында» 2019 ел, 6 сентябрь, 795 нче.

3. Бу карар имза куелган көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин